ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Об обеспечении доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг в Республике Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 июня 2017 года

## Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон регулирует отношения в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг.

## Статья 2. **Правовое регулирование отношений в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг**

1. Правовое регулирование отношений в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг основывается на Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан и осуществляется в соответствии с Федеральным законом от 24 ноября 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации» (далее – Федеральный закон) и принимаемыми в соответствии с ним другими федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом, другими законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

2. Органы местного самоуправления в пределах своей компетенции имеют право издавать муниципальные правовые акты, регулирующие отношения в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг, в соответствии с федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской

Федерации, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

Статья 3. **Понятия, используемые в настоящем Законе**

Основные термины и понятия, применяемые в настоящем Законе, используются в том же значении, что и в Федеральном законе.

Статья 4. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг**

1. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан относятся:

1) принятие законов Республики Татарстан, регулирующих отношения в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг;

2) осуществление контроля за соблюдением и исполнением законов Республики Татарстан, регулирующих отношения в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг;

3) осуществление иных полномочий в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан относятся:

1) утверждение государственных программ Республики Татарстан, предусматривающих мероприятия в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг, а также осуществление контроля за реализацией указанных программ;

2) издание нормативных правовых актов в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг;

3) осуществление иных полномочий в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

3. К полномочиям органов исполнительной власти Республики Татарстан в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг относятся:

1) участие в разработке и реализации государственных программ Республики Татарстан, предусматривающих мероприятия в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг;

2) обеспечение условий доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур, находящихся в собственности Республики Татарстан;

3) осуществление мониторинга в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг;

4) осуществление иных полномочий в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

Статья 5. **Объекты социальной, инженерной и транспортной инфраструктур, подлежащие оснащению специальными приспособлениями и оборудованием**

К объектам социальной, инженерной и транспортной инфраструктур, подлежащим оснащению специальными приспособлениями и оборудованием для обеспечения доступности для инвалидов, относятся:

1) жилые здания государственного и муниципального жилищного фонда;

2) административные здания и сооружения;

3) объекты культуры и культурно-зрелищные сооружения, культовые здания и места отправления религиозных обрядов;

4) объекты и организации образования, науки, здравоохранения, социальной защиты, социального обслуживания и занятости населения;

5) объекты торговли, общественного и бытового обслуживания населения, кредитные учреждения, помещения для осуществления нотариальной деятельности;

6) гостиницы (отели), иные места временного проживания;

7) физкультурно-оздоровительные, спортивные здания и сооружения, места отдыха, парки, сады, лесопарки, пляжи и находящиеся на их территории объекты и сооружения оздоровительного и рекреационного назначения, аллеи и пешеходные дорожки;

8) объекты промышленного назначения, объекты малого бизнеса, производственные объекты, в которых в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан допускается трудоустройство инвалидов;

9) объекты и сооружения транспортного обслуживания населения: железнодорожные вокзалы, автовокзалы, аэропорты, другие объекты автомобильного, железнодорожного, водного и воздушного транспорта, обслуживающие население;

10) станции и остановки всех видов транспорта в городском, пригородном и междугородном транспортном сообщении;

11) здания и сооружения связи и информации;

12) тротуары, переходы улиц, дорог и магистралей.

Статья 6. **Обеспечение условий доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг**

Органы государственной власти Республики Татарстан, органы местного

самоуправления (в сфере установленных полномочий), организации независимо от их организационно-правовых форм обеспечивают инвалидам (включая инвалидов, использующих кресла-коляски и собак-проводников) условия доступности объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг в соответствии с Федеральным законом.

Статья 7. **Участие общественных объединений инвалидов в обеспечении доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг**

1. Общественные объединения инвалидов имеют право на объективную, достоверную и полную информацию о доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур, расположенных на территории Республики Татарстан, предоставляемых в них услугах и о мероприятиях в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг.

2. Общественные объединения инвалидов вправе обращаться в органы государственной власти Республики Татарстан и органы местного самоуправления с предложениями по обеспечению доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг.

3. Представители общественных объединений инвалидов вправе принимать участие в проведении мониторинга в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг.

Статья 8. **Контроль за обеспечением доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг**

Контроль за обеспечением доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг осуществляется в соответствии с нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 9. **Финансовое обеспечение затрат в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг**

1. Финансовые затраты, связанные с выполнением норм настоящего Закона в части обеспечения доступности для инвалидов вновь строящихся и действующих объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур, несут

собственники указанных объектов.

2. Финансирование мероприятий государственных программ Республики Татарстан, муниципальных программ в сфере обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур и предоставляемых в них услуг осуществляется за счет соответствующих бюджетов и других источников финансирования, не запрещенных федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

3. Финансовое обеспечение расходных обязательств, связанных с исполнением настоящего Закона за счет средств бюджета Республики Татарстан, осуществляется в пределах бюджетных ассигнований, предусматриваемых в законе о бюджете Республики Татарстан на соответствующий финансовый год и на плановый период на указанные цели.

Статья 10. **Вступление в силу настоящего Закона**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

2. В соответствии с федеральным законодательством положения настоящего Закона в части обеспечения доступности для инвалидов объектов социальной, инженерной и транспортной инфраструктур применяются исключительно ко вновь вводимым с 1 июля 2016 года в эксплуатацию или прошедшим реконструкцию, модернизацию указанным объектам.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
23 июня 2017 года
№ 41-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), аның нигезендә кабул ителә торган башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә үз компетенцияләре кысаларында социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм

аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган муниципаль хокукый актлар кабул итәргә хокуклы.

3 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп терминнар һәм төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

4 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнары кабул итү;

2) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тору;

3) федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә чаралар үткәрү күздә тотыла торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау, әлеге программаларның үтәлешен тикшереп тору;

2) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итү;

3) федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

3. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген

тәэмин итү өлкәсендә чаралар үткәрү күздә тотыла торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

2) Татарстан Республикасы милкендәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан инвалидларның файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итү;

3) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә мониторинг үткәрү;

4) федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр башкару.

5 статья. **Махсус җайланмалар һәм җиһаз урнаштырылырга тиешле социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектлары**

Инвалидларга файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өчен махсус җайланмалар һәм җиһаз урнаштырылырга тиешле социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларына түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак биналары;

2) административ биналар һәм корылмалар;

3) мәдәният объектлары һәм мәдәният-тамаша корылмалары, дини биналар һәм дини йолаларны башкару урыннары;

4) мәгариф, фән, сәламәтлек саклау, социаль яклау, халыкка социаль хезмәт күрсәтү һәм халыкны эш белән тәэмин итү объектлары һәм оешмалары;

5) сәүдә, халыкка җәмәгать һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтү объектлары, кредит учреждениеләре, нотариаль эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыннары;

6) кунакханәләр (отельләр), башка вакытлыча яшәү урыннары;

7) физкультура-сәламәтләндерү, спорт биналары һәм корылмалары, ял итү урыннары, парклар, бакчалар, урман-парклар, пляжлар һәм аларның территорияләрендәге сәламәтләндерү һәм рекреация билгеләнешендәге объектлар һәм корылмалар, аллеялар һәм җәяүлеләр өчен юллар;

8) федераль һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру рөхсәт ителә торган сәнәгать билгеләнешендәге объектлар, кече бизнес объектлары, җитештерү объектлары;

9) халыкка транспорт хезмәте күрсәтү объектлары һәм корылмалары: тимер юл вокзаллары, автовокзаллар, аэропортлар, автомобиль, тимер юл, су һәм һава транспортының халыкка хезмәт күрсәтә торган башка объектлары;

10) шәһәр, шәһәр яны һәм шәһәрара транспорт элемтәсендә барлык төр транспорт станцияләре һәм тукталышлары;

11) элемтә һәм мәгълүмат биналары һәм корылмалары;

12) тротуарлар, урамнар, юллар һәм магистральләр аша чыгу урыннары.

6 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итү**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (билгеләнгән вәкаләтләре өлкәсендә), оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар Федераль закон нигезендә социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның (кресло-колякаларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итәләр.

Статья 7. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеге өчен шартлар тудыруны тәэмин итүдә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре катнашуы**

1. Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеге турында һәм социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге чаралар хакында объектив, дөрес һәм тулы мәгълүмат алырга хокуклы.

2. Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча тәкъдимнәр белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3. Инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре вәкилләре социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә мониторинг уздыруда катнашырга хокуклы.

8 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне тикшереп тору**

Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген

тәэмин итүне тикшереп тору Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге чыгымнарны финанс белән тәэмин итү**

1. Әлеге Закон нормаларын яңа төзелә торган һәм гамәлдәге социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә үтәүгә бәйле финанс чыгымнары күрсәтелгән объектларның милекчеләренә йөкләнә.

2. Социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт программалары, муниципаль программалар чараларын финанслау тиешле бюджетлар, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тыелмаган башка финанслау чыганаклары исәбенә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Законны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән үтәүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда әлеге максатларга карала торган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

10 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Федераль законнар нигезендә әлеге Закон нигезләмәләре социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан инвалидларның файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә бары тик 2016 елның 1 июленнән генә кулланылышка тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән күрсәтелгән объектларга карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2017 ел, 23 июнь
№ 41-ТРЗ